**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены карары**

01 ноябрь 2022 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Адав-Толымбай авылында юлларны төзекләндерү, зиратларны төзекләндерү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, часовня территориясен төзекләндерү эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы _________ А.Ф. Әхмәтҗанов

Халык җыены секретаре _________ Г.Ш. Насертдинова